**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРТА БАЛТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2021 ел, 3 март №26

**Апас муниципаль районының Урта Балтай авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2008 елның 25 нче декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авыл җирлегенең Советы карар **бирә:**

1. «Апас муниципаль районының Урта Балтай авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының 2017 елның 7 августындагы 61 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районының Урта Балтай авыл җирлеге депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:

- 1 пунктның 8 пунктчасын үз көчен югалткан дип санарга;

9 пунктчаны 8 пунктча дип санарга;

- түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктын өстәргә:

«2.1.Әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра. Җирлек Советы депутатының муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат күрсәтелгән белешмәләрне депутат булып сайланган, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырган яисә даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны туктаткан көннән алып дүрт ай эчендә, шулай ук белешмәләр (хисап чоры) бирелү елыннан алдагы һәр ел эчендә, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр башкарылган очракта, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләрнең хисап чоры дәвамында башкарылган очракта тапшыра. Хисап чорында мондый алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына хәбәр итә.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Урта Балтай җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Урта Балтай авыл**
**җирлеге Башлыгы** **И.М. Гәрәев**